**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 22 октябрь № 796

г. Казань

2016/2017 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләү программаларын – һөнәри укытуның төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнарын һәм күләм нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016/2017 уку елына түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләү программаларын – һөнәри укытуның төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең норматив чыгымнарын;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләү программаларын – һөнәри укытуның төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең күләм нормативларын.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015/2016 уку елына Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнарны һәм һөнәри әзерләүне тормышка ашыруга хезмәтләр күрсәтү күләмнәре нормативларын раслау турында» 2014 ел, 1 октябрь, 703 нче карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2016 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\796.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 22 октябрь, 796 нчы
карары белән расланды

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләү программаларын – һөнәри укытуның төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ**

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше (белгечлек) | Уку-өйрәнү вакыты, ай | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнар, бер кешегә сум | |
|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр җирлеге | авыл җирлеге |
| 16185 | Тегү җиһазлары операторы | 3 | 4357 | 4927 |
| 16675 | Пешекче | 4 | 5313 | 5966 |
| 19203 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 5 | 8218 | 9346 |
| 19861 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер | 5 | 7512 | 8491 |

_______________________________

F:\KARAR\2015\796.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 22 октябрь, 796 нчы
карары белән расланды

Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләү программаларын – һөнәри укытуның төп һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең

**КҮЛӘМ НОРМАТИВЛАРЫ**

| Әзерлек юнәлеше (белгечлек) коды | Әзерлек юнәлеше (белгечлек) | Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителүче хөкем ителгән затларны һөнәри әзерләүгә норматив чыгымнар, бер кешегә сум |
|---|---|---|
| «87 нче Мамадыш һөнәр көллияте» ДАҺББУ | | |
| 16185 | Тегү җиһазлары операторы | 40 |
| 19203 | Авыл хуҗалыгы җитештерүе тракторчы-машинисты | 20 |
| 19861 | Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер | 20 |
| 16675 | Пешекче | 20 |

_______________________________